

Краснослободск районы Усть-Рахмановка авылы район vзәгеннән ерак урнашкан – глубинкада; ишектән чыккачтын табигать сезне vз кочагына ала торган матур урында. Авылнын барлыкка килv тарихын искә алыйк. Шулай, Рахмановка елгасы буенда урнашкан авылга унжиденче гасырда темник татарлары нигез салган. 15 йортлы моселман мәчетле казна жирлегеннән кvп су агып киткән инде. Узган гасырлар эчендә урман ягындагы авылнын чәчәк аткан еллары да булган: 329 ойдә 1950 кеше яшәгән. Районнын борынгы кvп кенә авыллары кебек vк, Усть-Рахмановка да бик кvп vзгәреш жилләрен кичерде.       Ә хәзер нәрсә барын били шул: унлап яшәv йорты бар, тик барысында да кышларга калмыйлар авыл халкы. Биредә яшәvче топ халыкны бармак белән санарлык. Жәен, әлбәттә, авыл халык белән шактый тула; яздан бакча сезонын ачучылар байтак. Бу авылда картаеп жиргә vскән йортлар да бар. Агач йортларнын тузган тvбәләрен, буш кvзле тәрәзәләрен чvп vләннәре аша кvрv чиксез авыр хисләр тудыра; хужасыз йортлар vзләренен гасырын яши бирәләр. Әмма чисталык, тәртип, тозеклек һәм авыл матурлыгына игътибарны жәлеп итеп утырган матур йортлар да бар. Бу хужалыклар vзләренен тозеклеге, яшәv шартлары, шау чәчәккә торенгән клумбалары, бакчаларынын похтәлеге белән шәһәрнен кайбер йорт тозелеше белән бәхәсләшә алыр иде. Мондый ойләр башкалар ориентирлаша торган маяклар кебек утыралар.
Усть-Рахмановка авылы Нагорный исемле бер урамнан тора. Биредә тормыш табигать кочагында vтә һәм ул ботенләй башкача, vз кагыйдәләре буенча тозелә. Авыл халкында уртаклык хисе тирән сакланган, чонки биредә һәрвакыт бердәм булып, ярдәмләшеп яшиләр. Топ кыйммәт, әлбәттә, кеше-ләр; алар аз булсалар да һәрберсе турында кvп нәрсә сойләргә була. Әйтик, дачник Нәбиулла Абдрахман улы Тугушев һәрвакыт «Беларусь» тракторы белән ярдәмгә килергә әзер. Ул башкарып чыга алмаган очракларда, гусеницалы тракторында Илдар Таһир улы Алтышов ярдәмгә килә. Авылда бар нәрсә уч тобендә тосле: калкулыкта Акчуриннар йорты, анын капкасы каршында кечкенә генә кәнәфи - утыргыч бар. Ул кечкенә авыл жыеннарынын кvптәнге урыны; тирә-кvрше белән аралашырга яки моһим мәсьәләләр буенча фикер алышырга кирәкле утыргыч. Анда утырып хужабикә Лидия Михайловна белән район гәзите корреспонденты Татьяна Фокина сойләшкән. Ә гаиләнен ир-ат яртысы кvрше районга ашлык алырга киткән.
«Гомумән алганда, без яхшы гына яшибез, - ди пенсионер ханым. - Хужалык тотабыз,

дорес, сыерны сатарга туры килде. Безгә, пенсионерларга, аны асрау авыр булды. Ә менә аттан баш тартмыйбыз. Бу безнен кvрше авылга икмәк, азык-толек алырга бару транспорты. Һәм башка максатларда да ат бик тә кирәк. Тавыкларны ишегалдында тотабыз, кечкенә умарталыгыбыз бар. Безнен конкvреш жайлаштырылган. Авылда табигый газ, электр ут, ә кое суын вакуум насосы белән ойгә тарттырабыз. Керне - кер юу машинасы юа. Азык - толекне суыткыч, тундыру камерасында саклыйбыз. Авыл халкы очен санузеллар да яналык тvгел. Тик без ваннадан гына баш тартабыз. Кvнелебезгә мунчалар хуш килә, ә бакчачыларнын жәйге душлары да бар». Әйтеп китәргә кирәк, Лидия Михайловна берничә дистә ел элек Ковылкино районынын Котракс бистәсеннән Сәмиулла Абдулла улына киявгә чыгып, ике улын табып, бу якны яраткан. Егерме жиде ел жирле кибеттә (ябылганчы) сатучы булып эшләгән. Ул сәвдә иткән кызыл кирпечтән тозелгән бина авыл vзәгендә утыра һәм анын оеннән дә әйбәт кvренә. Йозакта медпункт, клуб кебек vк, мәктәп тә.

«Безнен барыбыз очен дә ин моһим проблемаларнын берсе – трассадан авылыбызга кадәр асфальт юл юклыгы, - ди Лидия Михайловна. - Жәйге корылыкта юл аша vтеп була, коз-кышларын яхшы vтә торган техникада гына йорергә була. Ә ул ботен кешедә дә юк. Юлсыз яшәргә бигрәк кышын авыр. Хәер, сонгы елларда безнен юлларны вакыт-вакыт чистарталар. Һәм без моны оештыручыларга рәхмәтле».

Әнгәмәдәшебез Камиль Хисаметдин улы Акмаев та сvзгә кушыла: «Кайчагында безнен юлга кар шундый кvп иттереп тутыра, бу проблеманы авыл хакимияте белән тиз генә хәл итеп булмый, - дип ости. - Жирле бюджетта бу максатларга акча юк, бигрәк тә техника табуы читен. Кемнедер ялларга кирәк. Гаделлек очен шуны да әйтә алам, Колопинка авыл жирлегенен элекке башлыгы (без шул авыл жирлеге карамагында) олешчә юл проблемасын хәл итvгә иреште: юлнын чокырлы бер участогында су агу очен торба салдыртты, вак таш тvшәгәннәр. Монын очен дә зур рәхмәт ана».

Усть-Рахмановкалылар очен юл - тышкы доньяны тоташтыручы жеп. Кибетләрдән, якын-тирә авыллар базарларыннан яшәv очен кирәкле әйберләр алып кайтыр очен кирәк. Тvтәлләрдә дә, абзарларда барысын да vз кулларын белән vстереп булмый. Белгәнебезчә, авыл халкы - яхшы хезмәтчәннәр; бәрәнге, яшелчәләрне, жиләк – жимешләрне vстерvен-vстерә-ләр. Аларнын кайберләре теплицалар да тозегән. Хәтта жәйгә килvчеләр дә йомырка сала торган тавыклар vстерергә олгерә. Юл - туганнарынын, балаларынын һәм оныкларынын еш килv, вакытында ашыгыч медицина ярдәме кvрсәтv, куркынычсызлык хезмәтләре кvрсәтv очен бик кирәк. Рәхмәт сvзләре белән Колопино амбулаториясенен гомуми практика табибы А.В. Осин турында әйттеләр авыл кешеләре; Алексей әфәнде коне-тоне буе усть-рахманлыларга медицина ярдәме кvрсәтә.

Пенсия алу да авыл халкы очен катлаулы проблемага әйләнгән. Почтальонны кvптән кvргәннәре юк. Пенсия алучылар бер-ике генә булса да, алар арасында инвалидлар, тугызынчы дис-тәдәгеләре дә бар. Кvрше авылнын почта бvлекчәсенә кадәр юл йоз чакрымга якын, азмобиль кешеләргә бу юл - булдыра алмаслык ара. Тагын бер борчыган заманча мәсьәләне отставкадагы эчке эшләр министрлыгы (МВД) подполковнигы Искәндәр Ибраһим улы Грачев житкерде. Авылда барысы да кәрәзле телефоннардан файдалана, әмма урамнын тvбән олешендә элемтә булмый. Анын әйтvенчә, биредә яшәvчеләрнен скайп буенча якыннары белән аралашырга теләкләре зур.

«Мелиоводхоз» оешмасынын Ләмбе-рә филиалында пенсиягә чыкканчы тырышып хезмәт иткән акыллы һәм игелекле Камиль Хисаметдин улы Акмаев утыргычтагы әнгәмәдән сон,

авыл буйлап, бvгенге тормыш турында сөйләп, тобәкнен тарихи vткәненә әйләнеп кайтып, авыл белән таныштырды. Элеккеге клуб модире, авыл Советы депутаты, авыл халкы турында кайгырткан Захар Хисаметдин улы Алтышов йорты янында туктап, авылдашлары кvнелендә якты истәлек булып калган анын тормыш иптәше, кайгыртучан һәм игелекле хатыны турында да искә алдык. Бvген Алтышовлар йорты буш тора. Ә астарак, усть-рахманчыларнын  инде бvген бакыйлыкка кvчкән беренче укытучылары Галина Ивановна Капкаеванын куак арасыннан ое кvренеп тора. Ул бирегә яшь кыз булып килгән, 45 ел эшләгән. Мәчеттә балаларны укыта башлаган, ә аннары vз кулы белән мәктәп салдырган кеше. Тагы 1944 елда Берлинда фашистлар тарафыннан Муса Жәлил белән бергә жәзалап vтерелгән якташ шагыйрь һәм журналист Әхмәт Симаевнын исемен халык горурланып искә ала. Кызганычка каршы, бvген авылда анын турында бернинди дә истәлекле урын исән калмаган. Шулай ук Боек Жинvгә зур олеш керткән очен Кызыл Йолдыз ордены белән бvләкләнгән И.И.Грачевны, III һәм II дәрәжә Дан ордены белән бvләкләнгән Х.Х. Акмаевны, ике Кызыл Йолдыз ордены, I һәм II дәрәжә Ватан сугышы ордены белән бvләкләнгән О.А.Тугушевны хормәт белән искә алды Камиль Хисаметдин улы. Алар - жинvчеләрнен даны белән горурланучы әнгәмәдәшләрнен каһарман әтиләре, шушы ерак авыл кешеләре.
Истәлекләрне янартып авыл белән танышуны дәвам итәбез. Тирә-якта бушлык, ә табигать бушлыкка тvзми. Моны кvрергә авыр. Жинелчә жилдә баганаларындагы кvчәр тирәсендә кулдан ясалган флюгерлар - башлары киселгән пластик шешәләр әйләнә. «Бу кулдан ясалган әйберләр кротларны куркыту очен, - дип эшне белеп анлата Камиль Хисаметдин улы Акмаев. - Кимерvчеләр безнен чишмәне дә боздылар дип уйлыйбыз. Кvптән тvгел уртак тырышлык белән борынгы чишмә остендә яна агач бура урнаштырдык. Әмма кvпмедер вакыттан сон, судан кvнелсез ис килә башлады. Суга анализ ясатырга кирәк, тик бу мәшәкатьле эш, диләр.
Һичшиксез, тобәк экологиясе vзгәр-де. Заманында биредә колхоз бар иде. Кvп еллар авыл тирәсендә басулар эшкәртелми; алар каеннар, башка кыргый vсемлекләр очен унайлы туфракка әверелде. Элек кешеләр жирне урман янында яулаган, хәзер урман авылга килә. Барысы да яхшы булыр иде, тик коры vләнгә ут кабу куркынычы яный. Авыл халкы vзләре йорт тирәләрендәге территорияләрне чаба, әмма буш яткан барлык участокларны vзләре генә башкарып чыга алмый. Кайчандыр кулдан казылган буа да ләм белән каплана...»
Проблемаларга карамастан, Усть-Рахмановкада кунакчыл, юмарт, эчкерсез, тырыш кешеләр яшәгәнче авыл да яшәр. Кечкенә Ватаныбызнын ерак авылы кvкрәк тутырып чиста саф һаваны сулаган балалары, оныклары булганга да яшәячәк. Менә олыгайган К.Х.Акмаевнын оныгы Радик та бабакае белән чәчәкләр vстерергә яраткан әбисе Халидә Әхмәт кызынын хәлен белергә, шулай ук vзенен техникасы белән шогыльләнергә килгән. Анын гаражы янында чын мәгънәсендә ретро-машиналар кvргәзмәсе. Бу йортта утлар сvнмәгән әле.

**Наилә Насырова**